| ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНБЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.07.2016 г. Казань № 281-п.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2015 елның 07 августындагы № 342-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Татарстан Республикасында этләрне теркәү буенча административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

2014 елның 1 декабрендәге “Инвалидларның хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” № 419-ФЗ Федераль законның 26 статьясының 4 өлешендәге 2 пункты нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең норматив-хокукый актларын законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2015 елның 07 августындагы № 342-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Татарстан Республикасында этләрне теркәү буенча административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктны түбәндәге эчтәлекле яңа кызыл юл белән тулыландырырга:

“Дәүләт хезмәте фәнни, фәнни-тикшеренү, медицина оешмалары өчен фәнни тикшеренү объектлары булган этләрне асрау өлкәсендәге мөнәсәбәтләргә кагылмый.”;

1 бүлекнең 1.3 пунктындагы 1.3.4 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле яңа кызыл юл белән тулыландырырга:

“Мәгълүмат такталарына урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турындагы белешмәләрне үз эченә ала.”;

1.5 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа кызыл юлны өстәргә:

“1995 елның 24 ноябрендәге “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” № 181-ФЗ Федераль закон (РФ Законнар җыентыгы, 27.11.1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);”;

икенче-унынчы кызыл юлларны өченче-унынчы кызыл юллар итеп санарга;

2.4 пунктның “Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге” графасын түбәндәге эчтәлекле икенче кызыл юл белән тулыландырырга:

“Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган”;

2.14 пунктның аталышын түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә:

“2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү биналарына карата, шул исәптән, Россия Федерациясенең социаль яклау турындагы законнарына туры китереп, аталган объектларның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә карата, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларны урнаштыруга һәм тиешенчә җайлаштыруга карата таләпләр”;

2.14 пунктның “Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге” графасын түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәтен алучыларны кабул итү бу максатлар өчен махсус бүлеп бирелгән, түбәндәгеләр белән җиһазланган урыннарда башкарыла:

этне карау өчен остәл;

тиешле медицина җиһазлары;

янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;

документларны рәсмиләштерү һәм саклау өчен кирәкле җиһаз;

ветеринария препаратларын саклау өчен җиһаз;

мәгълүмат такталары.

Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга каршылыкларсыз барып җитү мөмкинлеге тәэмин ителә (биналарга җайлы керү һәм аннан җайлы чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү).

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен, шул исәптән инвалидларның чикле мөмкинлекләрен исәпкә алып, җайлы урыннарда урнаштырыла”;

2.15 пунктта:

“Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге” графасын түбәндәге эчтәлекле яңа кызыл юл белән тулыландырырга:

“инвалидларга аларга башка затлар белән беррәттән хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне үтеп чыгарга ярдәм итү;”;

икенче-ундүртенче кызыл юлларны өченче-унбишенче кызыл юллар итеп санарга.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары А.Р. Гәрәевне җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе башлыгы в.б. А.Р.Гәрәев